| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.05.2023 Казан ш № 420

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законны үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры Р.Р.Фәйзуллинга Регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Н.В.Бутаевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.05.2023 ел, № 420 боерыгы белән расланды

**Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1.1. Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

анда даими яшәү урыны буенча яшәүче, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашучылар, һәлак булган (үлгән) сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының гаилә әгъзалары булып торган затлар, I һәм II төркем инвалидлар, инвалид балалар;

анда даими яшәү урыны буенча яшәүче, гаилә составында Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашучылар, I һәм II төркем инвалидлар, инвалид балалар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк бала, һәлак булган (үлгән) сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының гаилә әгъзалары булган затлар;

җан башына исәпләгәндә гаиләнең кереме 19 000 сумнан артмаган, даими яшәү урыны буенча яшәүче йорт хуҗалары.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү (алга таба – субсидия).

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең) исеме

2.2.1. Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк, Үзәк бүлекчәсе).

2.2.2. Күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки), техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) шәхси кабинетына җибәреп.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.5. Субсидия бирү турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

### 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша электрон документлар формасында җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар имзаланган көндә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар күчермәсе мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчегә субсидия бирү турында (бирүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан субсидия бирү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (язма рәвештә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә) аны бирү турында карар кабул ителгән көнне хәбәр ителә.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

субсидия алу ысулын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән);

2021 елның 21 апреленнән соң подряд оешмасы белән төзелгән, йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү буенча эшләр башкаруга подряд шартнамәсе күчермәсе;

йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү буенча башкарылган эшләр актының күчермәсе;

йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү буенча башкарылган эшләр өчен түләүне раслаучы документлар;

сатып алынган йорт эчендәге газ җиһазлары өчен түләүне раслаучы документлар, паспорт күчермәләре белән;

төзелеп беткән газ бүлү системасы объектын кабул итү актының яки тоташтыру (технологик тоташтыру) турында актның күчермәсе, анда якларның мөлкәте һәм эксплуатация җаваплылыгы чикләнгәнлеге турында мәгълүмат була;

аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак бинага хокук билгеләүче документның күчермәсе;

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә субсидия билгеләү өчен, мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы документ күчермәсе;

Бөек Ватан сугышы ветераннарына, сугыш хәрәкәтләре ветераннарына, һәлак булган (үлгән) сугыш ветераннарының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының гаилә әгъзаларына субсидия билгеләү өчен, мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзасының Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннарына, һәлак булган (үлгән) сугыш инвалидының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының гаилә әгъзалары категорияләренә каравын раслый торган документ күчермәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала тууын дәүләт теркәве турындагы документ күчермәсе һәм аның рус теленә нотариаль рәвештә расланган тәрҗемәсе (булган очракта);

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән, өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында документ күчермәсе һәм аның рус теленә нотариаль рәвештә расланган тәрҗемәсе (булган очракта);

мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларыннан яисә аларның законлы вәкилләреннән (ялгыз яшәүче гражданиннан кала) ирекле формада документ (документлар), түбәндәгеләрне раслаучы:

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

шәхси мәгълүматларны Үзәк бүлекчәсенә тапшырганда мөрәҗәгать итүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын;

ышанычлы затлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе күчермәсе.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр, аларның тормыш хәлләренә карап, өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшыралар:

мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының тулы дәүләт тәэминатында булуы турында (опекадагы балалардан тыш);

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның 23 яшьтән кечерәк гаилә әгъзаларының көндезге уку формасы буенча урта һөнәри һәм югары белем бирү учреждениесендә белем алу факты турында;

23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча белем алган очракта, стипендия алмау факты турында;

мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаиләсе әгъзаларының чакырылу буенча хәрби хезмәт үтүе турында;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының суд карары буенча мәҗбүри дәвалауда булуы турында;

мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чарасын куллану турында;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы фән-педагогика кадрларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре күләме турында;

отставкага киткән судьяларга гомер буе ай саен түләнә тәэминат күләме турында;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендәге хезмәттән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узуны күздә тотылган башка органнардагы хезмәттән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында;

хәрби хезмәт, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү

органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнарда хезмәт итүче (хезмәт иткә) затлар ала торган пенсия күләме турында;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарның хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты (акча белән тәэмин итеп тору), шулай ук даими холыкка ия булган өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән азык-төлек тәэминаты (азык-төлек паегы урынына акчалата субсидия) күләме турында;

Россия Федерациясе Җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, федераль иминлек хезмәте органнары, Россия Федерациясе дәүләт саклау органнары, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлеге белән бәйле федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең керемнәре турында (Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләреннән тыш);

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре керемнәре турында;

дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган, алынган субсидия күләме турында;

мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан Россия Федерациясеннән читтә алынган керемнәр күләме турында;

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр һәм шәхси практиканы гамәлгә ашырудан кергән керемнәр күләме турында;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзалары алган алиментлар күләме турында;

акцияләр буенча керемнәр һәм оешманың милек идарәсендә катнашудан кергән башка керемнәр турында;

кредит оешмаларында кертемнәр буенча алынган процентлар турында;

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында;

мирас итеп алынган һәм бүләк ителгән акчалар турында;

Россия Федерациясе Салым кодексының 217[1] статьясында күрсәтелгән сроктан азрак вакыт эчендә милектә булган күчемсез милекне сатудан, шулай ук

мөлкәтне арендага (наемга, поднаемга) бирүдән алынган керемнәр турында.

2.6.2. Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.6.3. Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтагы белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Гариза электрон рәвештә тапшырылган очракта, физик зат тарафыннан бирелгән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итү хокукын раслаучы ышанычнамә нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән раслана.

2.6.4. Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.6.5. Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

2.6.6. Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкысының электрон формасы, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) (http://mtsz.tatar.ru) урнаштырылган.

2.6.7. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

Үзәк бүлекчәсенә шәхсән яисә почта аша кәгазьдә;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша (техник мөмкинлек булганда).

2.6.8. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.6.9. Гаризаны һәм кирәкле документларны «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга)

тиеш.

2.6.10. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар (белешмәләр):

яшәү урыны буенча теркәлү турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

инвалидлык һәм аның төркеме турында (булган очракта); Рәсми мөрәҗәгать Федераль медицина-социаль экспертиза бюросына җибәрелә;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

никахлашуны (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында. Рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрелә;

баланы опека билгеләнүе турында. Рәсми мөрәҗәгать җирле үзидарә органнарына җибәрелә;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукларындагы чикләүләрне гамәлдән чыгару турында белешмәләр, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы йолып алу турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать җирле үзидарә органнарына җибәрелә;

хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү турында. Рәсми мөрәҗәгать  Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

керемнәрне исәпкә алуның исәпләнгән чорында эшкә яраксыз затларны карау турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә.

2.6.11. Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

2.6.12. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.13. Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча карамаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бер тапкыр субсидия бирү турында» 2022 елның 18 февралендәге 137 номерлы карары нигезендә йорт хуҗалыгы участогы чикләрендә газ кертүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бер тапкыр бирелә торган субсидияне элегрәк алган мөрәҗәгать итүченең гариза белән мөрәҗәгать итүе.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы;P80

әлеге Регламентның 1.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен гаиләнең җан башына уртача кереме күләме 19 000 сумнан артып китүе;

гаризада дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар булуы;

әлеге Регламентның 1.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең һәм (яки) аларның гаиләләренең эшкә сәләтле әгъзаларының керемнәре булмавы, түбәндәге очраклардан тыш:

мөрәҗәгать итүче яки аның гаиләсенең эшкә сәләтле әгъзасы өч яшькә кадәрге баланы карый;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаиләсенең эшкә сәләтле әгъзасы I төркем инвалидны, 18 яшькә кадәрге инвалид баланы, шулай ук дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган яки 80 яшькә җиткән өлкән кешене карый;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаиләсенең эшкә сәләтле әгъзасы гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яки югары белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча белем ала һәм стипендия алмый.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып

чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы ял (бәйрәм) көне булып саналмаган эш көнендә, ә гариза эш көне тәмамланганнан соң алынган очракта, икенче эш көнендә теркәлә.

### 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла, көтү заллары (бүлмәләре) мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителә, аларда Үзәк бүлекчәсенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат, шулай ук, тутыру үрнәкләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларның рәвешләре урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект

территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;

бүлек биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан Регламентны бозуга нигезле шикаятьләр булмау.

2.13.3. Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.5. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.13.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык (http://mtsz.tatarstan.ru) сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан алынырга мөмкин.

2.13.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт

хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында БИАС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә җибәрелә. БИАС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.3. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын

күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

Алдан язылу булмау мөрәҗәгать итүчене чират тәртибендә кабул итүгә комачауламый.

2.14.3. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гаризалар төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хата) төзәтү.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Үзәк бүлекчәсе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Үзәк бүлекчәсенең вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында

мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

3.2.1. Гариза бирүче шәхсән, телефон, почта аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша Үзәк бүлегенә дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк бүлеге белгече шәхсән, телефон аша, почта, электрон почта ярдәмендә, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча, гариза бланкы бирә һәм, зарурлык булганда, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче субсидия билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлегенә, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктына туры китереп, документларны теркәп тапшыра.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

Үзәк бүлегенә почта аша, шул исәптән электрон почта буенча, җибәрелгән гариза гомуми тәртиптә карала.

3.3.2. Үзәк бүлеге хезмәткәре дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаганда, Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры турында тамгалап (гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), гаризаны гариза бирүчегә язу тапшыру, почта аша, шул исәптән электрон почта аша, хәбәрләмә җибәрү (документлар почта, шул исәптән электрон почта, аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булган очракта, Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә документларны кайтарып бирә һәм гариза бирүчегә, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуда ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза һәм документлар почта аша, электрон почта аша электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлегенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлегенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән язу, документларны кабул итүдән баш тарту турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә баш тарту турында хәбәр итү, мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Үзәк бүлекчәсенең ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган белгече әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

3.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган белешмәләрнең исемлеге:

яшәү урыны буенча теркәлү турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

инвалидлык һәм аның төркеме турында (булган очракта); Рәсми мөрәҗәгать Федераль медицина-социаль экспертиза бюросына җибәрелә;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

никахлашуны (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында. Рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрелә;

баланы опека билгеләнүе турында. Рәсми мөрәҗәгать җирле үзидарә

органнарына җибәрелә;

ата-航аналык хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукларындагы чикләүләрне гамәлдән чыгару турында белешмәләр, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы йолып алу турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать җирле үзидарә органнарына җибәрелә;

хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү турында. Рәсми мөрәҗәгать  Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

керемнәрне исәпкә алуның исәпләнгән чорында эшкә яраксыз затларны карау турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә  дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

3.4.4. Әлеге Регламентның 2.6.10 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә,  кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.10 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә

ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.5. Субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар әзерләү.

3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган белешмәләр нигезендә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның законлы вәкиле яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

субсидия бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 3 нче кушымтасындагы форма буенча субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар проекты рәсмиләштерә;

субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар проектын имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә электрон рәвештә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап килгән көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураларның нәтиҗәсе: субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында электрон рәвештә карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе документларны караганнан соң электрон цифрлы имза белән субсидия бирү (бирүдән баш тарту турында) турында электрон рәвештәге карарны имзалый һәм Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура документларны субсидия бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карар проекты җибәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе имзалаган субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында рәсмиләштерелгән карар.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлекчәсе белгече субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (мөрәҗәгать итүченең почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта каралган процедураларны үтәү срогы:

мөрәҗәгать итүчегә субсидия бирү (бирүдән баш тарту турында) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү субсидия бирү (бирүдән баш тарту турында) турында карар кабул ителгән көнне башкарыла.

Субсидия бирү турында (бирүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар турында хәбәр ителгән мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, субсидия бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карарның күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында хәбәр итү, мөрәҗәгать итүчегә субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар күчермәсен шәхсән тапшыру.

3.7. Техник хаталарны төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 4 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.7.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә электрон рәвештә юллый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган, субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән электрон рәвештәге карар.

3.7.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе электрон цифрлы имза белән субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән электрон рәвештәге карарны имзалый һәм Үзәк бүлекчәсе белгеченә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе имзалаган субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.

3.7.3. Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча), субсидия билгеләү (субсидия билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү.

3.8. Күпфункцияле үзәк аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ аша гамәлгә ашырылмый.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Әлеге Регламентның административ процедураларында билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүне агымдагы контрольдә тоту Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламентның нигезләмәләрен саклау һәм үтәү буенча

тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибен һәм рәвешләрен Үзәк директоры билгели.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Министрлык Аппараты бүлегенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль районында һәм шәһәр округында Министрлыкның социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турындагы нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентлары белән билгеләнә.

Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.3. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.4. Әлеге Регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Үзәкнең, Үзәк бүлекчәсенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, әлеге Регламентны үтәү өчен җаваплы булып, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк, Үзәк бүлекчәсе эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карау мөмкинлеге аша

гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (учреждение белгече) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны гариза бирүчедән таләп иткәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең), дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт хезмәткәренең, орган (учреждение) җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatarsta№.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органда вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул

ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча гариза бирүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение белгече булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Үзәк бүлекчәләренең, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №___________
бүлекчәсе

_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА 20____ елның «_____» ________

Мин,____________________________________________________________________,
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
түбәндәге адрес буенча яшим:
________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

эш итү нигезе: ___________________________________________________________
(гариза бирүченең дәүләт хезмәтенән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

Йорт хуҗалыгы участогы чикләрендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирүне сорыйм

________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры ______________

Гаилә составы (даими яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә яшәүче гражданнар күрсәтелә):

| т/с | Фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) | Туу датасы | СНИЛС | Туганлык дәрәҗәсе | Шәхесне раслаучы документ (серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән, бүлекчә коды) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | Мөрәҗәгать итүче | |
| 2 | | | | | |

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:
счетка күчерү юлы белән
_________________________________________________________________________
(Мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яисә законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
почта бүлеге аша
_________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта бүлеге, ышанычлы зат яки законлы вәкил реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым

Мөрәҗәгать итүче:__________________________ _________ «__»______ 20__ ел.

(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы)

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза:

| | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|
| почта адресы буенча язма рәвештә: ________________________________________ | |
| электрон почта адресы буенча электрон документ формасында: ________________________________________________ | |
| «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша | |

«__»________ 20__ ел. Имза ______________

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел. _________ ______________________________________________________________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

__________________________________________________________________________

Өзү линиясе
Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №_________
Документлар саны ____ данә, __ биттә
Документларны кабул итте ___________ _________ _____________ ______ 20__ ел.
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

Йорт хуҗалыгы участогы
чикләре эчендә газ үткәрү һәм
йорт эчендәге газ җиһазларын
сатып алуга бәйле чыгымнарны
каплауга субсидия бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| Т/с | Мөрәҗәгать итү датасы | Мөрәҗәгать номеры | Гражданинның ФИА | Адресы | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать нәтиҗәләре | Сәбәпләре күрсәтелмәгән мөрәҗәгать нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге ДКУ №___ бүлекчәсе
_______________________ муниципаль районында (шәһәр округында)

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында карар

№ ______ «______» ___________________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) _____________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________________

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга _____________ сум күләмендә субсидия бирергә.

Түләү ысулы _____________________________________________________

Бүлек җитәкчесе _________________________ ________________________
(Ф.И.А.) имза

Мөһер урыны

Бүлек белгече _________________________ ________________________
(Ф.И.А.) имза

Гариза бирүчегә хәбәр ителде:

| | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|
| почта адресы буенча язма рәвештә: ____________________________________ | |
| электрон почта адресы буенча электрон документ формасында: ____________________________________________ | |
| «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша | |

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ
№ _______________ бүлекчәсе
____________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирүдән баш тарту турында карар

№ _____ «__» _____________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ________________________________________________

Йорт хуҗалыгы участогы чикләрендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирүдән баш тартырга.
Баш тарту сәбәбе: ______________________________________________________________.

Бүлек җитәкчесе __________________________ __________________________
(Ф.И.А.) имза
Мөһер урыны
Бүлек белгече __________________________ __________________________
(Ф.И.А.) имза
Гариза бирүчегә хәбәр ителде:

| | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|
| почта адресы буенча язма рәвештә: ______________________________________ | |
| электрон почта адресы буенча электрон документ формасында: ______________________________________________ | |

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №___________ бүлекчәсе

______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хата төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
яши торган адрес

___________________________________________________________________________
__(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
___________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең шәхесен раслаучы документның исеме, сериясе, номеры, бирелгән датасы, документны биргән орган атамасы) техник хатаны төзәтү турында сорыйм

______________________________________________________________,
йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү (бирүдән баш тарту турында) турында карарда җибәрелгән

__________________________________________.
(карар реквизитлары, бирелү датасы)

Йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында (бирүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар алуга килешәм:

| | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|
| почта адресы буенча язма рәвештә: ___________________________________ | |
| электрон почта адресы буенча электрон документ формасында: __________________________________________ | |

«__» ________ 20__ ел. _____________________ ____________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)